ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**V чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**V созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
14.11.2025 ел

**РЕШЕНИЕ**
№02-09

**Актаныш муниципаль районы Советының 2012 елның 16 мартындагы 16-03 номерлы «Актаныш муниципаль районы территориясендә көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерүне һәм эшкәртүне оештыру турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 343-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2012 елның 16 мартындагы 16-03 номерлы «Актаныш муниципаль районы территориясендә көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерүне һәм эшкәртүне оештыру турындагы Нигезләмәне раслау хакында"гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлегенең 6 пунктындагы 10 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Калдыкларны урнаштыру объектлары-калдыкларны, шул исәптән җир асты байлыкларыннан файдалану калдыкларын урнаштыру өчен каралган (1992 елның 21 февралендәге «Җир асты байлыклары турында» 2395-I номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә кулланылырга тиешле ачылмалы һәм сыйдырышлы тау токымнарын саклау объектларыннан тыш) һәм үз эченә калдыкларны саклау объектларын һәм калдыкларны күмү объектларын алган махсус җиһазландырылган корылмалар;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Совет рәисе Л.Р.Зарипов